ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь, 2018 ел № 28/7

2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) раслау турында

2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планын (программасын) кушымтага нигезләнеп расларга.
2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
28/7 Карарына
кушымта
11 декабрь, 2018 ел

**2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планы (программасы)**

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы, алга таба – Фараз планы) 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ санлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп эшләнгән.
2. 2019 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, шәһәр бюджеты керемнәрен арттыруга юнәлтелгән.
3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә туры китереп, законда каралган ысуллар белән башкару күздә тотыла.

2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

4. 2019 елда муниципаль казнада торучы һәм муниципаль предприятиеләрдә, учреждениеләрдә файдалануда булмаган күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.
5. Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/9 санлы Карары белән расланган 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) кергән, агымдагы елда хосыйлаштырылмаган объектлар хосусыйлаштырыла

| № | Исеме | Урыны | Мәйданы кв.м | Фаразланган хосусыйлаш-тыру вакыты |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1** | Торак булмаган бина, 1 кат | ТР, Яр Чаллы шәһәре, Вахитов проспекты, 28 йорт (30/03), 3 нче подъезд | 8,8 | I-II кварталлар |
| **2** | Торак булмаган бина, 1 кат | ТР, Яр Чаллы шәһәре, Шамил Усманов урамы, 30 йорт (41/17), 1 нче подъезд | 6,5 | I-II кварталлар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Торак булмаган бина, 1 кат | ТР, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 74 йорт (28/01), 9 нчы подъезд | 9,6 | I-II кварталлар |
| 4 | Торак булмаган бина, 1 кат | ТР, Яр Чаллы шәһәре, Раскольников урамы, 71А йорты (12/17), 1 нче подъезд | 13,1 | I-II кварталлар |
| 5 | Торак булмаган бина, 1 кат | ТР, Яр Чаллы шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 63 йорт (52/13), 8 нче подъезд | 16,3 | I- II кварталлар |

6. 2019 елда муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль милектә булган акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

7. Күчемсез милекне хосусыйлаштыру һәм хосусыйлаштыру шартлары турында, шул исәптән, тартып алу белән бер үк вакытта затка сатылган милекне һәм әлеге милек биләгән һәм аннан файдалану өчен зарури булган җир кишәрлеген хосусыйлаштыру шартлары турында карар Шәһәр Советы Карарлары нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

8. 2019 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлегенә Фараз планының гамәли вакытында Шәһәр Советы Карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре милкен хосусыйлаштыруның мәгълүмати тәэмин ителеше

9. Яр Чаллы шәһәре милкен хосусыйлаштыру турында мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм тагын да киңрәк рекламалау максатында, Башкарма комитет әлеге Фараз планының үтәлеше барышында федераль законда каралган тәртиптә массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән файдаланырга хокуклы.